**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«16» 01 2023 ел Яр Чаллы №04

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге “Изумрудный поселогы” территориясен планлаштыру документларын карау буенча халык тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган (Тукай муниципаль районы Советының 2022 елның 9 декабрендәге 27/8 номерлы карар нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

## КАРАР БИРӘМ

1. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге «Изумрудный поселогы» территориясен планлаштыру документларын карау буенча халык тыңлауларын үткәрергә.
2. Халык тыңлауларын бер көндә, 2023 елның 9 февралендә 13:00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: Кече Шилнә авыл җирлеге, Кече Шилнә авылы, Үзәк ур., 4а.
3. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп О.А. Никитинаны билгеләргә.
4. Проект буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.
5. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
7. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2023 елның 16.01 04 номерлы карарына кушымта

## Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге тәртип проект буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм район гражданнарының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.

2. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе – җомга, 9:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12:00 сәгатьтән 13:00 сәгатькә кадәр).

3. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatar.ru) урнаштырылырга тиеш.

4. Проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2023 елның 19 январеннән 2023 елның 8 февраленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.

5. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.

6. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.

7. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.

8. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә: чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә; проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр; фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.

9. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

10. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә: халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме; халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны; халык тыңлауларында катнашкан гражданнарның саны; халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

11. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм ул мәҗбүри рәвештә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.